**АКТАНЫШСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423740,село Актаныш, Проспект Ленина, дом 58.Тел.3-44-40

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 нче йорт. Тел.3-44-40

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«25» октябрь 2024 ел** **№ 11**

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Актаныш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибе турында» Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 21 октябрендәге 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 10 октябрендәге 1360 номерлы карары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Актаныш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 21 октябрендәге 16 номерлы карарына (17.07.2020 елдан 14 номерлы, 04.10.2024 елдан 10 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 **1 бүлегенең 5 пунктында**:

а) **3 пунктчада** "хисаплылыктан өземтә" сүзләрен "белешмә" сүзенә алмаштырырга.;»

б) **4 пунктчада** "Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160_1 статьясы нигезендә бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү буенча бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Регламентында каралган"сүзләрен өстәргә.;

в) **5 пунктчада** җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"амнистия турында акт яисә штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата ярлыкау акты яисә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычны, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, түләтү мөмкинлеген югалта торган суд акты;";

түбәндәге эчтәлекле **абзац өстәргә**:

"гражданның судтан тыш банкротлыгы процедурасын тәмамлау турында банкротлык турында белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ.".;

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Актаныш авыл башкарма
комитеты җитәкчесе К.Н.Әхмәтгалиев

ОГРН 1061682000071
р 06-37/09
АКТАНЫШСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИНН 1604006783